
# Уку эшчәнлеген оештыруда кагыйдәләр.

- **Иң әһәмиятлесе шул: уку хезмәтендә билгеле бер максатың булсын.**
- **Шуны исеңдә тот: максатчан кеше уңышка ирешә.**
- **Син алган белем киләчәктә халкыбызга хезмәт итсен.**


Кушма җөмлә
Ике компонентлы кушма ж.
Катлаулы кушма ж.
Тезмә кушма ж.
Иярченле кушма ж.
Теркәгечле тезмә к.ж.
Теркәгечсез тезмә к.ж.
Аналитик иярченле к.ж.
Синтетик иярченле к.ж.
Ия җөмлә
Хәбәр җөмлә
Аергыч җөмлә
Тәмамлык җөмлә
Хәл җөмлә
Аныклагыч җөмлә
Вакыт ж.
Урын ж.
Рәвеш ж.
Күләм ж.
Сәбәп ж.
Максат ж.
Шарт ж.
Кире ж.

# Кушма җөмлә



# Өй эшен тикшерү.

Күләм җөмләләр файдаланып, “Чаңгы ярышында” темасына кечкенә хикәя төзергә.

Сорау: чаңгы спортының кеше өчен нинди әһәмияте бар?

# Бүген дәрестә:

<u>Иярчен сәбәп җөмлә. Аның аналитик һәм синтетик төрләре.</u>

Үзләштерергә тиешле белем һәм күнекмәләр: иярчен сәбәп җөмләне тану, синтаксик яктан тикшерү, сөйләмдә дөрес куллану.

# Иярчен сәбәп җөмләне өйрәнү планы.

1. Иярчен сәбәп җөмләнең функциясе.
2. Иярчен сәбәп җөмләнең сораулары.
3. Иярчен сәбәп җөмләнең бәйләү чаралары.
4. Иярчен сәбәп җөмләнең аналитик һәм синтетик төрләре.
5. Сөйләмдә кулланылышы.

# Иярчен сәбәп җөмләнең функциясе.

1. Баш җөмләдәге сәбәп хәленең эшен башкара.
2. Баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән сәбәп хәлен ачыклый:(шуңа күрә, шуның өчен, шунлыктан, шул сәбәпле, шуның аркасында)

# Иярчен сәбәп җөмләнең сораулары.

1. Ник?
2. Нигә?
3. Нилектән?
4. Ни өчен?
5. Ни сәбәпле?
6. Нәрсә аркасында?

# Иярченле кушма җөмләдә бәйләү чаралары

**Аналитик чаралар**

- Мөнәсәбәтле сүзләр
- Ияртүче теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр
- Көттерү интонациясе

**Синтетик чаралар**

- Кушымчалар
- Бәйлек һәм бәйлек сүзләр
- Янәшәлек

# Сәбәп җөмләне бәйләүче аналитик чаралар.

1. **Ялгыз мөнәсәбәтле сүзләр:** шуңа күрә, шуның өчен, шул сәбәпле, шунлыктан, шуның аркасында.
2. **Күтәрү интонациясе.**
3. **Ияртүче теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр:** чөнки, ки, ник дисәң, ник дигәндә.

# Сәбәп җөмләне бәйләүче синтетик чаралар.

1.Килеш кушымчалары: -га,гә; -ка,-кә; -дан, -дән(салкынга);

2.Үткән заман сыйфат фигыль формасы + юнәлеш килеш кушымчасы( булганга);

3.Исем фигыль формасы + чыгыш килеш кушымчасы: ( эшләүдән);

4.Сүз ясагыч кушымча –лык,-лек + чыгыш килеш кушымчасы(уйлаганлыктан).

# 1. Кайсы кушма җөмләдә иярчен сәбәп җөмлә бар?

1. Шуны исегездә тотыгыз: сәламәтлек – иң зур байлык.
2. Теләге бар үз сәламәтлеген ныгытыр.
3. Вакытыгызны дөрес бүләргә өйрәнегез, чөнки сәламәтлек өчен эш һәм ялны бүлә белү дә бик кирәк.
4. Кыш җиткәч, чаңгыда һәм тимераякта шуу да бик файдалы.

# 2.Иярчен сәбәп җөмләнең төзелеше буенча төрләрен билгелә.

1. Физкультура һәм спорт – сәламәт тәнле һәм саф акыллы булу өчен төп шарт, шуңа күрә сезгә даими шөгыльләнергә кирәк.

2. Витаминлы азыклар ашау сәламәтлек өчен мөһим булганга, дөрес туклану турында да онытмагыз.

## 3. Нокталар урынына сәбәп җөмләләрне бәйләүче чаралар кулланыгыз.

**1.Ул елны көз бик коры килде, … кыр эшләре иртә бетте.**(Г.Г.)

**2.Көчле буран булган..., машиналар бер урыннан кузгала алмый тордылар.**(А.Ш.)

**3.Китмибез без: безгә анда мондагыдан эш кыен.**(Г.Т.)

**4.Ләкин безгә алар белән танышырга туры килмәде, … без анда өч-дүрт көн генә тордык.**(Ш.К.)

# Дәреслек белән эш.

- 98 нче бит, 130 нчы күнегү.1,2,4 җөмләләр.
- 1,2  нче  җөмләләрнең  схемаларын төзергә, тулы исемнәрен язарга;
- 4 нче җөмләне синтаксик яктан тикшерергә.

# Иярченле кушма җөмләне тикшерү тәртибе.

1. Грамматик нигезләрне табабыз. Ике гади җөмләнең чиген билгелибез.
2. Баш һәм иярчен җөмләләрне аерабыз.
3. Җөмләнең схемасын төзибез, бәйләү чарасын һәм тыныш билгеләрен күрсәтәбез, баш җөмләдән иярчен җөмләгә сорау куябыз.
4. Җөмләнең тулы исемен атыйбыз.

# Биремнәрнең үтәлешен тикшерү.

1.**(Монда әле неводчылар килеп җитмәгән<u>гә</u>,)** тачкачылар гына эшләп маташа иде.(Ш.К.)

2.**(Бәдри кит<u>ү сәбәпле)</u>,** Хәлим налогны үзе генә җыярга булды.

# Җөмләләрне синтаксик яктан тикшерергә.

**Мин Тукайдан үрнәк алам дисең,**
**Бу түбәнлек түгел, һич түгел,**
**Чөнки Тукай халык моңнарының**
**Бакчасында тибрәп үскән гөл.**

# Тест биремнәрен үтәгез.

1. Иярчен җөмлә-

а) иярченле кушма җөмләдә беренче җөмлә;

б) иярченле кушма җөмләдә соңгы җөмлә;

в) ияреп килгән һәм баш җөмләдән сорау куеп булган җөмлә;

г) дөрес җавап бирелмәгән.

## 2. Иярчен җөмләнең мәгънәсе буенча төрен нәрсәгә карап билгелиләр?

а) сораудан чыгып билгеләнә;

б) бәйләү чарасына карап билгеләнә;

в) иярчен җөмләнең урынына карап билгеләнә;

г) дөрес җавап бирелмәгән.

# 3. Кайсы рәттә ияркчен сәбәп җөмлә сораулары?

а) нинди? кайсы?

б) ничек? ни рәвешле?

в) нилектән? нәрсә аркасында?

г) кайда? кая?

# 4.Иярчен җөмләнең төзелеше буенча төрен  нәрсәгә карап билгелиләр?

а) иярчен җөмләнең мәгънәсенә карап;

б) иярчен җөмләнең сорауларына карап;

в) иярчен җөмләләрне бәйләүче чарага карап;

г)иярчен җөмләнең урынына карап.

5. **(...), шуңа юллар югалды**. Бу җөмләгә кайсы иярчен җөмлә туры килә?

а) Җылы язлар җиткәч;

б) Ак күбәләкләр очкан шикелле;

в) Кичә бик күп кар яуды;

г) Әйтер сүзем шул.

# 6.Синтетик иярчен сәбәп җөмләсе булган кушма җөмләне табыгыз.

а) Дәү әнисе татар китаплары яратканга күрә, өйдә ана телендәге китаплар шактый иде.(И. Ә.)

б) Монда эш кайный, шуңа күрә күңелле.(М. Г.)

в) Намус шөрепләрең какшаган синең, шуңа йөрәгем әрни.(М.Н.)

г) Ә төннәрен мин иңемә шинель салам:җәйге төндә су салкыны нык сиздерә.(Х. С.)

# 7. Кайсы рәттә аналитик бәйләү чаралары бар?

а) кушымча, бәйлек, янәшәлек;

б) ияртүче теркәгеч, мөнәсәбәтле сүз, көттерү паузасы;

в) санау интонациясе, тезүче теркәгеч;

г) каршы кую интонациясе.

# 8.Аналитик иярчен сәбәп җөмлә янында нинди тыныш билгеләре куела?

а) сызык;

б) өтер, ике нокта;

в) берни дә куелмый;

г) өтер генә куела.

# Җаваплар:

1. в;
2. а;
3. в;
4. в;
5. в;
6. а;
7. б;
8. б.

# <u>Эшләрне бәяләү:</u>

хаталар юк  -  “5”

1-2 хата бар  – “4”

3  хата бар  – “3”

4  хата һәм күбрәк  – “2”

# Өй эше.

1) мәжбүри;  дәреслекнең 95 нче бите, 123 нче күнегү, биремне үтәргә;

2) ирекле; сәбәп җөмлә кулланып, “Шәһәребездә Тукай һәйкәле” темасына мәкалә язарга.